ЛЕНИНОГОРСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
ЛЕНИНОГОРСК РАЙОН
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

Лениногорск ш.

2018 елның 27 сентябре №56

**Лениногорск муниципаль районы Советының «Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 19 декабрендәге 98 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

2018 елның 3 августындагы 307-ФЗ номерлы “Россия Федерациясенең аерым закон актларына коррупциягә каршы тору турындагы законнарының үтәлешен тикшереп торуны камилләштерү максатларында үзгәрешләр кертү турында”гы Федераль закон, “Лениногорск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасының “Лениногорск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» Лениногорск муниципаль районы Советының 2013 елның 19 декабрендәге 98 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

19 статьяның 19.4.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2.1 пунктчасы өстәргә:
коррупциячел һәм коррупциячел хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау докладының (анда аны башкаруның факттагы шартлары бәян ителә) һәм муниципаль хезмәткәрне аның ризалыгы белән генә һәм коррупциячел хокук бозуны кылу фактын тану шарты белән (ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендәге хокук бозулардан тыш) муниципаль хезмәткәрне язмача аңлатуы);".

2.Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лениногорск муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Н.Г. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Лениногорск муниципаль районы башлыгы,
муниципаль район Советы рәисе Р.Г.Хөсәенов